ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ
КОМИТЕТ ГОРОДА
ИННОПОЛИС

ул. Спортивная, д.114, г.Иннополис,
Верхнеуслонский район,
Республика Татарстан, 420500

ИННОПОЛИС
ШӘҺӘРЕНЕҢ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

Спортивная ур., 114-нче йорт, Иннополис
шәһәре, Югары Ослан районы, Татарстан
Республикасы, 420500

тел. (843) 212-27-24, e-mail: city@innopolis.ru, www.verhniy-uslon.tatarstan.ru/rus/innopolis.htm

ПОСТАНОВЛЕНИЕ
21.09.2022

Иннополис шәһәре

КАРАР
69

Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районы «Иннополис шәһәре» муниципаль берәмлеге территориясендә җылылык белән тәэмин итү өлкәсендә гарантияле оешманы билгеләү турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 14 статьясы, «Җылылык белән тәэмин итү турында» 2010 елның 27 июлендәге 190-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районының «Иннополис шәһәре» муниципаль берәмлеге территориясендә үзәкләштерелгән, өзлексез җылылык белән тәэмин итүне тәэмин итү максатларында Иннополис шәһәре Башкарма комитеты

КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районының «Иннополис шәһәре» муниципаль берәмлеге территориясендә салкын су белән тәэмин итү һәм ташландык суларны агызу өлкәсендә гарантияләүче оешма статусын Татарстан Республикасы, Казан шәһәре, Чуйков урамы, 2нче йорт, лит Б. адресы буенча урнашкан «ТАТКОММУНЭНЕРГО» Республика җитештерү берләшмәсе акционерлык җәмгыятенә бирергә.

2. «ТАТКОММУНЭНЕРГО» Республика җитештерү берләшмәсе Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районы «Иннополис шәһәре» муниципаль берәмлеге территориясендә җылылык белән тәэмин итү системаларын эксплуатацияләү буенча үз эшчәнлегендә «Җылылык белән тәэмин итү турында» 2010 елның 27 июлендәге 190-ФЗ номерлы Федераль закон белән җитәкчелек итәргә.

3. «ТАТКОММУНЭНЕРГО» Республика җитештерү берләшмәсе акционер җәмгыятенә Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районының «Иннополис шәһәре» муниципаль берәмлеге территориясендә урнашкан салкын су белән тәэмин итү һәм ташландык суларны агызу челтәрләренә тоташтырылган абонентларны, шулай ук капиталь төзелеш объектларын законда билгеләнгән тәртиптә җылылык белән тәэмин итәргә.

4. «Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районының «Иннополис шәһәре» муниципаль берәмлеге территориясендә җылылык белән тәэмин итү өлкәсендә гарантияле оешманы билгеләү турында» 2018 елның 15

декабрендәге 67 номерлы Иннополис шәһәре Башкарма комитеты карарын үз көчен югалткан дип танырга.

5. Әлеге карарны 7 көн эчендә Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (http://pravo.tatarstan.ru), Югары Ослан муниципаль районының Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында (http://verhniy-uslon.tatarstan.ru) бастырырга.

6. Әлеге карарны «ТАТКОММУНЭНЕРГО» Республика җитештерү берләшмәсе акционерлык җәмгыяте адресына җибәрергә.

7. Әлеге карар рәсми басылып чыккан (халыкка җиткерелгән) вакыттан үз көченә керә.

8. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Башкарма комитет җитәкчесе-торак-коммуналь хуҗалык, төзекләндерү, төзелеш һәм архитектура бүлеге башлыгы С.А. Беловага йөкләргә.

Җитәкче И.Р. Хуззәтов